# Демоверсия вариант КИМ по учебному предмету родной язык (татарский) для 2-4 классов

# 2 класс

**Контроль күчереп язу**
**Җәй**

Мин авылда  яшим. Авыл  янында урман бар. Җәй көне без җиләккә барабыз. Күлдә балык тотабыз. Мин авылны яратам.(18 сүз)

**Контроль күчереп язу**
**Шамил.**

Шамил укудан кайтты. Ул бик шат. Бүген аңа бишле билгесе куйдылар. Шамил укытучыны игътибар белән тыңлый. Дусларына булыша. Өйдә әнисенә булыша. (21 сүз)

**Контроль диктант**
**Кар ява.**

Кар ява. Тышта кар ява. Мамык төсле кар бөртекләре һавада бөтереләләр. Алар йолдызлар кебек җемелдиләр. Ак кар җир өстенә, авыл өйләренең түбәләренә куна.

# 3 класс

**Контроль күчереп язу**

Туган тел

Һәр милләт кешесенең үз туган теле бар. Ул беренче сүзен шушы телдә әйтә. Әнисе һәм әтисе аңа шул телдә эндәшәләр. Әнисе ана телендә бишек җыры җырлый. Дәү әнисе әкиятләр сөйли. Ата-ана теле җанга якын тел. Төрле милләт кешесе үз туган телендә беренче китабын укый. Иң изге телләрне дә ана телендә ишетә.

**Контроль диктант**

**Кышкы уен**

Тышта ак кар ява. Агач ботакларына мамыктай йомшак бәс куна. Бакча аеруча матур. Вәлигә бу күренеш бик ошый. Ул урамга чыга. Күрше малайлары белән бергәләп, бакча артындагы куаклыкта туйганчы уйнадылар. Алар йомшак кардан шар ясыйлар. Кайчакта кардан Кар бабай ясап куялар. ***(Г. Бакир буенча.)***

**Контроль диктант**

**Сыерчыклар килгән!**

Язгы җылы көннәрнең берсе иде. Улым бүлмәгә йөгереп керде дә, сыерчыклар килгәнне әйтте.

Без икәүләп өй алдына чыктык. Каен ботакларына берничә сыерчык кунган икән. Аларның чем-кара түшләре кояш нурларында җемелдәп тора.

# 4 класс

**Контроль күчереп язу**

**Үзсүзле Кызылтүш.**

Безнең якларда бик күп төрле кошлар бар. Алар ике төркемгә бүленгәннәр: кышлаучы һәм күчмә. Кышлаучы кошлар арасында бик тә матур кош бар –Кызылтүш. Ул нинди генә суыклар булса да, үз туган ягын ташлап китмәде. Төрле бөҗәкләр, коңгызлар, орлыклар белән туенды. Кыш уртасына кадәр урманда яшәде, ә аннан соң авылга килде. Шулай итеп, кышкы салкыннарны үткәрде.

**Контроль диктант**

**Декабрьдә**

Декабрь – кыш ае. Декабрьдә каты салкыннар башлана. Көннең иң кыска чоры шушы айда була. Басулар, урманнар-кар, елгалар боз белән каплана. Урман тын. Күп кошлар җылы якка киткән. Аю өнендә ята. Керпе, төлке, тиеннәр дә үзләренә оя ясаганнар. Агачларда яфрак урыныны бәс җемелди.

**Контроль диктант**

**Май**

Май-матур аяк басты туган ягыма!Майсыз кар бетми, дигән сүзне дөресләгәндәй, урмандагы коры елга төбендә дә карның эзе калмады. Җирне сусыл яшь үлән, агачларны озын һәм кызгылт песиләр, яшел яфраклар каплады. Хәзер кая карама шунда чәчәк… Табигать нинди иркен сулый!

**Критерии оценивания диктантов.**

| Отметка | Число ошибок (орфографических / пунктуационных) |
|---|---|
| «5» | 0/0, 0/1, 1/0 (негрубая ошибка) |
| «4» | 1/0, 1/1, 1/2, 2/1, 2/2, 1/3, 0/4; 3/0, 3/1 (если ошибки однотипные) |

| | |
|---|---|
| «3» | 3/0, 3/1, 3/2, 4/4, 3/3, 3/4, 3/5, 0/7, 5/4 , 6/6 (если ошибки однотипные или негрубые) |
| «2» | 5/9, 6/8, 7/7, 8/6 |

**Контрольное списывание**

«5» - за безукоризненно выполненную работу, в которой нет исправлений.

«4» - 1 ошибка или 1 – 2 исправления.

«3» - 2 – 3 ошибки.

«2» - 4 и более ошибок.